**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 25 февраль | № 117

г. Казань

2016 елга «Иннополис көллияте» дәүләт автоном белем бирү учреждениесенең дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм күләм нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елга түбәндәгеләрне расларга:

«Иннополис көллияте» дәүләт автоном белем бирү учреждениесендә балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар бер елга бер тәрбияләнүчегә 91 227 сум күләмендә;

2015/2016 уку елына «Иннополис көллияте» дәүләт автоном белем бирү учреждениесе күрсәтә торган хезмәтләрнең күләм нормативлары 120 тәрбияләнүче санында;

2016/2017 уку елына «Иннополис көллияте» дәүләт автоном белем бирү учреждениесе күрсәтә торган хезмәтләрнең күләм нормативлары 150 тәрбияләнүче санында;

«Иннополис көллияте» дәүләт автоном белем бирү учреждениесен финанслар белән тәэмин итү күләменә төзәтү коэффициенты 2,79702 зурлыгында.

2. Әлеге карарның көче 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\117.docx